ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_12.08.2019 г.__ М ө с л и м _420_

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 июнендә чыккан 305 номерлы «2019 елга торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә тарифларны раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын һәм алар өчен түләү күләменең нигезлелеген арттыру чаралары турында» 2010 ел, 9 апрель, 250 нче, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында» 2010 ел, 19 февраль, 85 нче карарларына карата, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРА:

1. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «2019 елга торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә тарифларны раслау турында» 2019 ел,24 июнь, 305 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә»:

1.1. Карар керешендә түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга: «Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 ел, 30 декабрь, 210 нчы карары, Федераль закон карары нигезендә», «Күпфатирлы йортлардагы торак биналарның милекчеләре һәм яллаучылар торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында Карар кабул итмәгәнлектән.»

1.2. Карарның 1 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

«1. Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына найм шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен һәм 1 нче кушымта нигезендә купфатирлы йорт белән идарә иту ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннарының милекчеләре өчен торак бинадан файдаланган өчен түләү күләмен ( наем өчен түләү) билгеләргә.»

1.3. Карарның 2 нче пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

«2. 2 нче кушымта нигезендә муниципаль торак фондыннан торак урыныннан (наем өчен түләү) файдаланган өчен түләү күләмен билгеләргә.»

1.4. Карарның 3 нче пунктын төшереп калдырырга.

1.5. Карарның 4 нче пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

«4. Әлеге карарны «Авыл Утлары» - «Сельские Огни» район газетасында бастырып чыгарырга. »

1.6. Карарның 5 нчы пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

«5. Әлеге карарның гамәлгә керүе 2019 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.»

1.7. Декарга 1 нче кушымтаны яңа эчтәлектә расларга.

1.8. Карарга 2 нче кушымтаны яңа эчтәлектә расларга.

2. Әлеге карарны «Авыл Утлары» - «Сельские Огни» район газетасында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И. Х. Әхмәтов

**Мөслим муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**«____» _______20___ел**
**____ карарына**
**1 нче кушымта**.

Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына найм шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен һәм 1 нче кушымта нигезендә купфатирлы йорт белән идарә иту ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннарының милекчеләре өчен торак бинадан файдаланган өчен түләү күләме
( наем өчен түләү)

| № | Хезмәт атамасы | Үлчәү берәмлеге | Түләү күләме, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | торак бинаның гомуми мәйданы 1 кв. м өчен аена | 1,56 |
| 2. | Капиталь ремонт (торак милекчеләреннән алына) | торак бинаның гомуми мәйданы 1 кв. м өчен аена | 5,85 |
| 3. | Торак бинаны ремонтлау һәм территорияләрне төзекләндерү | торак бинаның гомуми мәйданы 1 кв. м. өчен аена | 2,68 |
| 4. | Йорт эчендәге инженер челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту:<br><br>Сууткәргеч-канализация<br>Газ белән тәэмин итү челтәрләре<br>Электр белән тәэмин итү челтәрләре | торак бинаның гомуми мәйданы 1 кв. м. өчен аена | <br><br><br>1,34<br>0,21<br>0,73 |
| 5. | Йорт яны территорияләрен карап тоту һәм җыештыру | торак бинаның гомуми мәйданы 1 кв. м. өчен аена | 2,71 |
| 6. | Төтен юлларын һәм вентиляцион каналларны карап тоту һәм агымдагы | торак бинаның гомуми мәйданы 1 кв. м. өчен аена | 0,18 |

**Мөслим муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**«____» _______20___ел**
**____ карарына**
**2 нче кушымта**

Муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләме (наемга алынган өчен түләү)

| № | Хезмәт атамасы | Үлчәү берәмлеге | Түләү күләме, сум |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 1. | Яллану буенча база ставкасы | торак бинаның гомуми мәйданы 1 кв. м. өчен аена | 5,85 |